Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

29 апрель 2019 ел №291

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2009 елның 25 декабрендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре турында» №366 карарына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» №131-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 30, 33 статьялары, Әлмәт муниципаль районы Уставы нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2009 елның 25 декабрендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре турында» №366 карарына кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Кушымтаның график өлешен «Территорияне комплекслы һәм тотрыклы үстерү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру күздә тотылган яңа территория чикләре картасы» яңа картасы белән кушымта нигезендә тулыландырырга.

2. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтына урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны район Советының икътисадый үсеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм муниципаль милек мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Закиров Ш.К.).

Муниципаль район башлыгы А.Р. Хәйруллин

Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы Советының
2019 елның 29 апрелендәге 291 нче
карарына кушымта

Территорияне комплекслы һәм тотрыклы үстерү буенча эшчәнлекне
гамәлгә ашыру күздә тотылган яңа территория чикләре картасы



ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР:

——— территорияне комплекслы һәм тотрыклы үстерү буенча эшчәнлекне күздә тоткан территория чикләре

Муниципаль район башлыгы А.Р. Хәйруллин